ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№149 от «25» 05 2022 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә агынты суларның (агып чыгучы) үзәкләштерелгән ташландык суларны агызуның (канализациянең) системасына чыгаручы абонентлар өчен агынты сулар составы нормативларын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль закон, «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 07.12.2011 елның 7 декабрендәге № 416-ФЗ Федераль закон, «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 29 июлендәге № 644 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Агынты суларның составын һәм үзенчәлекләрен тикшереп тору кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм үз көчләрен югалтуларын тану турында» 2020 елның 22 маендагы № 728 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, әйләнә-тирәлеккә пычраткыч матдәләрнең тискәре йогынтысын, су объектларының пычрануын кисәтү максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә агынты суларның (агып чыгучы) үзәкләштерелгән ташландык суларны агызуның (канализациянең) системасына чыгаручы абонентлар өчен агынты сулар составы нормативларын расларга (1 нче Кушымта).

2.Мамадыш муниципаль районының үзәкләштерелгән ташландык суларны агызу системасына (канализация) агынты суларны агызучы (җибәрүче) барлык абонентларга юынты суларның составы нормативларын үтәүне тәэмин итәргә.

3.Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендә Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru/ рәсми сайтында һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

0000011421

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.М.Никифоровка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе

И.М.Дәрҗеманов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
25.05.2022 ел,
№ 149 санлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә агынты суларның (агып чыгучы) үзәкләштерелгән ташландык суларны агызуның (канализация) системасына чыгаручы абонентлар өчен агынты сулар составы нормативлары

| № п/п | Матдә (күрсәткеч)атамасы | Максималь рөхсәт ителгән күрсәткеч һәм (яки) концентрация (җыелма һәм табигый проба буенча), мг/дм (мг/л) |
|---|---|---|
| 1 | Аммоний-ион | 25 |
| 2 | АПАВ | 0,33 |
| 3 | БПК3 | 300 |
| 4 | Үлчәнгән матдә | 300 |
| 5 | тимер | 0,22 |
| 6 | Марганец | 0,3 |
| 7 | Нефть продуктлары | 0,07 |
| 8 | ХПК | 500 |
| 9 | Алтывалентлы хром | 0,02 |
| 10 | Сульфатлар | 100 |
| 11 | Фосфатлар фосфаты | 12 |
| 12 | Хлоридлар | 192 |
| 13 | феноллар | 0,007 |